КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 24 октябрь г.Казань № 919

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Азнакай муниципаль районындагы «Өмет» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе структурасын оптимальләштерү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәрендә «Восхождение» инвалидларны тернәкләндерү үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен төзү турында» 2007 ел, 29 декабрь, 771 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасының социаль яклау тармагы инфраструктурасын оптимальләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2025 елның 1 февраленнән «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Азнакай муниципаль районындагы «Өмет» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең (алга таба – Комплекслы үзәк) 36 койка-урынга исәпләнгән социаль-тернәкләндерү бүлеген бетерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

Комплекслы үзәк тарафыннан учреждение структурасын оптимальләштерү

чаралары үткәрелгәндә Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә;

2024 елның 30 ноябренә кадәр Комплекслы үзәккә оператив идарә хокукында беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтенең, шул исәптән күчемсез һәм аеруча кыйммәтле мөлкәтнең кайбер төрләрен алга таба файдалану турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына кертергә;

Комплекслы үзәк структурасын оптимальләштерүгә бәйле чараларны үткәрү чыгымнарын тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» ведомствосы буенча Комплекслы үзәк тарафыннан дәүләт биреме үтәлешен финанс белән тәэмин итүгә чыгымнар өлешендә каралган акча чикләрендә финанслауны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына 2025 елның 1 мартына кадәр Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтенең, шул исәптән күчемсез һәм аеруча кыйммәтле мөлкәтнең кайбер төрләрен алга таба файдалану турындагы тәкъдимнәр нигезендә Комплекслы үзәккә оператив идарә хокукында беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен тапшыруны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәрендә «Восхождение» инвалидларны тернәкләндерү үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен төзү турында» 2007 ел, 29 декабрь, 771 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 5 август, 682 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 2 пункттагы «102 койка-урынга (52 стационар һәм 50 ярымстационар урынга)» сүзләрен «80 койка-урынга (40 стационар һәм 40 ярымстационар урынга)» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

5. Бу карарның 4 пункты 2025 елның 1 февраленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин